**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 30 сентябрендәге 4103 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының**
**Техника урамында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 71 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:080115:104, 16:50:080115:101;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Техника урамы;
- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-493 трансформаторлы подстанция урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-493 трансформаторлы подстанциягә карата милек хокукы теркәлгән (2001 елның 26 декабре, №16-16-01/062/2008-1281.4).

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә

ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү буенча эшләр тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре Башкарма
комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4103 номерлы карары белән
расланды

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:100
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |

| | |
|---|---|
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:080115 | кадастр кварталы |
| 16:50:080115:104, 16:50:080115:101 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________